ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.05.2024 Олы Кайбыч ав. № 170

Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү һәм Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Кайбыч муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 133 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт хакы түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең хакын тәртипкә китерү һәм социаль гарантияләрне тәэмин итү максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 29 апрелендәге 287 номерлы «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмалар хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын күтәрү турында һәм «Бюджет өлкәсендә аерым оешмалар хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү хакында» карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. 2024 елның 1 июленнән Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Кайбыч муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 133 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә билгеләнә торган бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмаган бюджет даирәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсендә эшләүче Бердәм тариф челтәре кагылмый торган аерым оешмаларның җитәкчеләренә, белгечләренә һәм хезмәткәрләренә айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджет даирәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында аерым бюджет өлкәсен оештыруның структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладык күләмен 1,05 тапкырга индексацияләргә һәм аны 13 323 сум күләмендә билгеләргә.

3. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының «Бюджет даирәсендә эшләүчеләрнең хезмәт хакын түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган Кайбыч муниципаль районы бюджет өлкәсендәге аерым оешмалар хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге 133 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аерым оешмалар җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен бюджет өлкәсендәге аерым оешманың структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладлы күләмендә исәпләнә, ул 13 323 сум тәшкил итә.»;

- 1 пунктның 6 пунктчасының 3 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«төнлә эшләгән өчен (22 сәгатьтән 6 сәгатькә кадәр) - хезмәт законнарында һәм башка норматив хокукый актларда билгеләнгән күләмдә;»;

- 3 пунктның 3 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга;

- 7 пунктның 4 пунктчасында «15 процент» сүзләрен «37 процент» сүзләренә алмаштырырга».

4. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/ kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» бастырырга.

5. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров